ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 12 2022 г. № 937

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучыларга торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы нигезендә, Россия Төзелеш Министрлыгының 2022 елның 1 июлендәге 536/пр номерлы «Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучыларга торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында» 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» боерыгына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучыларга торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Нигезләмәнең 1 пунктындагы тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынын наемга алу өчен түләү коэффициенты тәңгәллеге күләме 0,057 күләмендә билгеләнә, дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урынын наемга алу шартнамәсе буенча бирелгән торак урынын наемга алу өчен – 1 күләмендә».

2. Әлеге карар 2023 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Ф. Булатов